СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.04.2026 Баулы шәһәре № 43

Баулы муниципаль район Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өлешендә аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указы нигезендә, норматив хокукый актларны актуальләштерү максатларында, Баулы муниципаль район Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 14 сентябрендәге 130 номерлы карарын;

- «Баулы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Баулы муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны, муниципаль хезмәт вазыйфаларын һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр,

чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирү Тәртибен раслау турында» от 2022 елның 27 октябрендәге 143 номерлы карарын;

-«Баулы муниципаль район Советының 2022 елның 27 ноябрендәге 143 номерлы карары белән расланган «Баулы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Баулы муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны, муниципаль хезмәт вазыйфаларын һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 2 февралендәге 163 номерлы карарын;

- «Баулы муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 14 сентябрендәге 130 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 сентябрендәге 218 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров